**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

2021 елның 18 июне №30

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

29 статьяның 4 пунктында «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы «Кама Тамагы
шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы - Совет рәисе Н. А.Вазыйхов